КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 апрель г.Казань № 268

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләре турында докладлар әзерләү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 ел, 17 июнь, 584 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләре турында докладлар әзерләү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 ел, 17 июнь, 584 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 август, 774 нче, 2023 ел, 06 ноябрь, 1425 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Россия Икътисади үсеш министрлыгы дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында (алга таба - статистик белешмәләр)» 2011 елның 21 декабрендәге 503 номерлы боерыгы белән расланган федераль статистик күзәтү формасы буенча белешмәләр» сүзләрен «Татарстан Республикасында дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләре турында докладлар» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Республика башкарма хакимият органнарына:»;

Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының

дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), гамәлгә ашыру вәкаләтләре гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары һәм республика башкарма хакимият органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына бирелгән төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре турында докладлар әзерләргә һәм урнаштырырга;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 20 февраленә кадәр, гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), гамәлгә ашыру вәкаләтләре гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары һәм республика башкарма хакимият органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына бирелгән төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре турында докладлар проектларын Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына килештерүгә җибәрергә. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы искәрмәләре һәм тәкъдимнәре белән килешмәгән очракта, килештерелгән позицияне эшләү максатыннан килештерү чараларын үткәрүне оештырырга;

Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген), төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген), гамәлгә ашыру вәкаләтләре гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары һәм республика башкарма хакимият органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына бирелгән төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру турында белешмәләр урнаштырырга.»;

3 пунктта:

икенче абзацта «төрләре турында» сүзләреннән соң «гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге),» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «Система ярдәмендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «һәм статистик белешмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «республика башкарма хакимият органнары,» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнары,» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта «һәм статистик белешмәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җирле үзидарә органнарына эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

гамәлгә ашыру вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына бирелгән төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында белешмәләр әзерләүне, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, оештырырга;

муниципаль контроль төрләре турында докладлар әзерләүне, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, оештырырга;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында мәгълүматларны аны гамәлгә ашыру вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына тапшырылган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре турында доклад әзерләү өчен төбәк контроль (күзәтчелек) органына җибәрергә;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр, муниципаль контроль төрләре турында докладларны муниципаль контроль төрләре турында докладларны гомумиләштерергә вәкаләтле җирле үзидарә органына гомумиләштерү өчен җибәрергә;

7 пунктта:

икенче абзацта «статистик белешмәләр» сүзләрен «муниципаль контроль төрен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан килештерелгән һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыклары имзалаган муниципаль контроль төрләре турында докладларны, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, урнаштырырга;

муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру турында белешмәләрне, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм срокларда һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы чыгара торган методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, урнаштырырга.»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин